ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2025 г. Казань № 646-147/тэ-2025

Казан шәһәренең «Органик синтез» Казан гавами акционер җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, башка җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга җибәрелә торган җылылык китерү матдәсенә 2026-2028 елларга тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2025 ел, №34-ПР идарә утырышы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәре «Органик синтез» гавами акционерлык җәмгыятеннән (алга таба – «Казаньоргсинтез» ГАҖ) кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга бирелә торган җылылык китерү матдәсенә әлеге карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2028 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2025 № 646-147/тэ-2025
карарына кушымта

«Казаньоргсинтез» ГАЖ кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга бирелә торган җылылык китерү матдәсенә 2026-2028 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Тариф төре | Ел | Җылылык чыганагы төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Су | Пар |
| | Кулланучыларга җибәрелә торган җылылык чыганагына тарифлар | | | | |
| | Казан шәһәре | | | | |
| | «Казаньоргсинтез» ГАЖ | бер ставкалы, сум/куб.м | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 82,18 | - |
| | | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 119,86 | - |
| | | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 74,86 | - |
| | | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 82,03 | - |
| | | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 74,03 | - |
| | | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 83,57 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге